**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан по вопросам противодействия коррупции

В связи с принятием Федерального закона от 22 декабря 2014 года № 431-ФЗ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации по вопросам противодействия коррупции» и в целях совершенствования деятельности по противодействию коррупции **постановляю:**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 30 декабря 2009 года № УП-701 «Об утверждении Перечня должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при назначении на которые граждане и при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей» (с изменением, внесенным Указом Президента Республики Татарстан от 5 октября 2011 года № УП-622) следующие изменения:

а) в наименовании, преамбуле, пункте 1, подпункте «а» пункта 2 слова «при назначении на которые граждане и» исключить;

б) в подпункте «в» пункта 2 слова «Департамент по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» заменить словами «Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан»;

в) в наименовании Перечня должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при назначении на которые граждане и при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей слова «при назначении на которые граждане и» исключить.

2. Внести в Положение о представлении гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики

Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении государственными гражданскими служащими Республики Татарстан сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 30 декабря 2009 года № УП-702 «О представлении гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении государственными гражданскими служащими Республики Татарстан сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711, от 16 мая 2012 года № УП-343, от 22 апреля 2013 года № УП-328 и от 24 сентября 2014 года № УП-920), следующие изменения:

а) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2. Обязанность представлять сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера возлагается на гражданина, претендующего на замещение должности гражданской службы (далее – гражданин).

Обязанность представлять сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера возлагается на государственного гражданского служащего Республики Татарстан (далее – гражданский служащий), замещавшего по состоянию на 31 декабря отчетного года должность гражданской службы, включенную в соответствующий перечень должностей гражданской службы, устанавливаемый Президентом Республики Татарстан (далее – Перечень должностей).»;

б) в пункте 3 слова «, предусмотренные Перечнем должностей» исключить;

в) в подпункте «в» пункта 6:

слова «если сумма сделки превышает общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих совершению сделки» заменить словами «если общая сумма таких сделок превышает общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду»;

слова «совершена сделка» заменить словами «совершены эти сделки»;

г) в пункте 7:

слова «претендующий на замещение должности гражданской службы, включенной в Перечень должностей» заменить словами «претендующий на замещение иной должности гражданской службы»;

слова «в соответствии с пунктами 2, 3 и 5» заменить словами «в соответствии с абзацем первым пункта 2, пунктами 3 и 5»;

д) в пункте 8:

в абзаце первом слова «на имя руководителя государственного органа Республики Татарстан (лица, замещающего государственную должность)»

исключить;

в абзаце втором слова «Департамент по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» заменить словами «Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан»;

е) в пункте 13:

слова «совершена сделка» заменить словами «совершены сделки (совершена сделка)»;

слова «если сумма сделки превышает общий доход лица, замещающего должность гражданской службы, и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих совершению сделки» заменить словами «если общая сумма таких сделок превышает общий доход лица, замещающего должность гражданской службы, и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду»;

ж) в абзаце втором пункта 15 слова «на должность гражданской службы, включенную в Перечень должностей» заменить словами «на должность гражданской службы, на замещение которой они претендовали».

3. Внести в Положение о представлении гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 11 января 2010 года № УП-4 «О представлении гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 мая 2012 года № УП-343, от 22 апреля 2013 года № УП-330, от 20 августа 2014 года № УП-797 и от 24 сентября 2014 года № УП-920), следующие изменения:

а) в подпункте «в» пункта 6:

слова «если сумма сделки превышает общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих совершению сделки» заменить словами «если общая сумма таких сделок превышает общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду»;

слова «совершена сделка» заменить словами «совершены эти сделки»;

б) в пункте 7 слова «на имя Президента Республики Татарстан» исключить;

в) в пункте 12:

слова «совершена сделка» заменить словами «совершены сделки

(совершена сделка)»;

слова «если сумма сделки превышает общий доход лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан, и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих совершению сделки» заменить словами «если общая сумма таких сделок превышает общий доход лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан, и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду».

4. Внести изменение в Положение о порядке размещения сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан и членов их семей на официальных сайтах государственных органов Республики Татарстан и предоставления этих сведений средствам массовой информации для опубликования, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 19 апреля 2010 года № УП-237 «Об утверждении Положения о порядке размещения сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан и членов их семей на официальных сайтах государственных органов Республики Татарстан и предоставления этих сведений средствам массовой информации для опубликования» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711, от 16 мая 2012 года № УП-343, от 14 августа 2013 года № УП-761 и от 20 августа 2014 года № УП-797), изложив подпункт «г» пункта 2 в следующей редакции:

«г) сведения об источниках получения средств, за счет которых совершены сделки (совершена сделка) по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимого имущества, транспортного средства, ценных бумаг, акций (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций) за отчетный период (с 1 января по 31 декабря), если общая сумма таких сделок превышает общий доход лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан (государственного гражданского служащего Республики Татарстан), и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду.».

5. Внести в Положение о комиссиях по соблюдению требований к служебному поведению государственных гражданских служащих Республики Татарстан и урегулированию конфликта интересов, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 25 августа 2010 года № УП-569 «О комиссиях по соблюдению требований к служебному поведению государственных гражданских служащих Республики Татарстан и урегулированию конфликта интересов» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан

от 6 ноября 2013 года № УП-1084, от 20 августа 2014 года № УП-797 и от 24 сентября 2014 года № УП-920), следующие изменения:

а) в пункте 15:

подпункт «б» дополнить абзацем следующего содержания:

«заявление государственного служащего о невозможности выполнить требования Федерального закона от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами» (далее - Федеральный закон «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами») в связи с арестом, запретом распоряжения, наложенными компетентными органами иностранного государства в соответствии с законодательством данного иностранного государства, на территории которого находятся счета (вклады), осуществляется хранение наличных денежных средств и ценностей в иностранном банке и (или) имеются иностранные финансовые инструменты, или в связи с иными обстоятельствами, не зависящими от его воли или воли его супруги (супруга) и несовершеннолетних детей;»;

подпункт «д» изложить в следующей редакции:

«д) поступившее в соответствии с частью 4 статьи 12 Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции» и статьей $64^1$ Трудового кодекса Российской Федерации в государственный орган уведомление коммерческой или некоммерческой организации о заключении с гражданином, замещавшим должность государственной службы в государственном органе, трудового или гражданско-правового договора на выполнение работ (оказание услуг), если отдельные функции государственного управления данной организацией входили в его должностные (служебные) обязанности, исполняемые во время замещения должности в государственном органе, при условии, что указанному гражданину комиссией ранее было отказано во вступлении в трудовые и гражданско-правовые отношения с данной организацией или что вопрос о даче согласия такому гражданину на замещение им должности в коммерческой или некоммерческой организации либо на выполнение им работы на условиях гражданско-правового договора в коммерческой или некоммерческой организации комиссией не рассматривался.»;

б) в пункте 18:

третье и четвертое предложения изложить в следующей редакции:

«В случае неявки на заседание комиссии государственного служащего (его представителя) и при отсутствии письменной просьбы государственного служащего о рассмотрении данного вопроса без его участия рассмотрение вопроса откладывается. В случае повторной неявки государственного

служащего без уважительной причины комиссия может принять решение о рассмотрении данного вопроса в отсутствие государственного служащего.»;

дополнить предложением следующего содержания:

«В случае неявки на заседание комиссии гражданина, замещавшего должность государственной службы в государственном органе (его представителя), при условии, что указанный гражданин сменил место жительства и были предприняты все меры по информированию его о дате проведения заседания комиссии, комиссия может принять решение о рассмотрении данного вопроса в отсутствие указанного гражданина.»;

в) дополнить пунктом $24^2$ следующего содержания:

«$24^2$. По итогам рассмотрения вопроса, указанного в абзаце четвертом подпункта «б» пункта 15 настоящего Положения, комиссия принимает одно из следующих решений:

а) признать, что обстоятельства, препятствующие выполнению требований Федерального закона «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами», являются объективными и уважительными;

б) признать, что обстоятельства, препятствующие выполнению требований Федерального закона «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами», не являются объективными и уважительными. В этом случае комиссия рекомендует руководителю государственного органа применить к государственному служащему конкретную меру ответственности.»;

г) в пункте 25:

слова «в подпунктах «а», «б» и «г» пункта 15» заменить словами «в подпунктах «а», «б», «г» и «д» пункта 15»;

слова «пунктами 21-24 и $24^1$» заменить словами «пунктами 21-24, $24^1$, $24^2$ и $25^1$».

6. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711 «О проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан, и соблюдения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан требований к служебному поведению» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 мая 2012 года № УП-343, от 6 ноября 2013 года № УП-1084 и от 24 сентября 2014 года № УП-920) следующие изменения:

а) в пункте 2:

в подпункте «з»:

слово «обеспечение» заменить словом «осуществление»;

слова «, а также проверки соблюдения гражданами, замещавшими должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, ограничений при заключении ими после ухода с государственной гражданской службы Республики Татарстан трудового договора и (или) гражданско-правового договора в случаях, предусмотренных федеральными законами» исключить;

дополнить подпунктами «л» и «м» следующего содержания:

«л) анализ сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан, сведений о соблюдении государственными гражданскими служащими Республики Татарстан требований к служебному поведению, о предотвращении или урегулировании конфликта интересов и соблюдении установленных для них запретов, ограничений и обязанностей, а также сведений о соблюдении гражданами, замещавшими должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, ограничений при заключении ими после увольнения с государственной гражданской службы Республики Татарстан трудового договора и (или) гражданско-правового договора в случаях, предусмотренных федеральными законами;

м) осуществление проверки соблюдения гражданами, замещавшими должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, ограничений при заключении ими после увольнения с государственной гражданской службы Республики Татарстан трудового договора и (или) гражданско-правового договора в случаях, предусмотренных федеральными законами.»;

б) в Положении о проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан, и соблюдения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан требований к служебному поведению:

в пункте 3 слова «претендующим на замещение должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, предусмотренной этим Перечнем должностей» заменить словами «претендующим на замещение иной должности государственной гражданской службы Республики Татарстан»;

в пункт 5 слова «Департамент по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» заменить словами «Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан».

7. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 6 ноября 2013 года № УП-1084 «О мерах по реализации отдельных положений

Федерального закона «О противодействии коррупции» и Федерального закона «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам» и о внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан по вопросам противодействия коррупции» (с изменениями, внесенными Указом Президента Республики Татарстан от 20 августа 2014 года № УП-797) следующие изменения:

а) в абзаце третьем подпункта «а», абзаце втором подпункта «б» пункта 1 слова «включенные в перечни, установленные нормативными правовыми актами Республики Татарстан» заменить словами «осуществление полномочий по которым влечет за собой обязанность представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей»;

б) в абзаце пятом подпункта «а» пункта 1 слова «включенные в перечни, установленные муниципальными нормативными правовыми актами» заменить словами «осуществление полномочий по которым влечет за собой обязанность представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей»;

в) в абзаце втором подпункта «в» пункта 1 слова «включенные в перечень, установленный нормативным правовым актом соответствующего государственного органа Республики Татарстан» заменить словами «осуществление полномочий по которым влечет за собой обязанность представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей»;

г) первое предложение абзаца второго пункта 3 изложить в следующей редакции:

«Основанием для принятия решения об осуществлении контроля за расходами лиц, указанных в пунктах 1 и 2 настоящего Указа, является достаточная информация о том, что данным лицом, его супругой (супругом) и (или) несовершеннолетними детьми в течение календарного года, предшествующего году представления сведений (далее – отчетный период), совершены сделки (совершена сделка) по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимости, транспортного средства, ценных бумаг, акций (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций) на общую сумму, превышающую общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду.»;

д) пункт 6 перед словами «иными нормативными правовыми актами Российской Федерации» дополнить словами «от 2 февраля 2015 года № УП-71 «О проверке достоверности и полноты сведений, представляемых

гражданами, претендующими на замещение должностей муниципальной службы в Республике Татарстан, и муниципальными служащими в Республике Татарстан, и соблюдения муниципальными служащими в Республике Татарстан требований к служебному поведению»,»;

е) в подпункте «б» пункта 9:

в абзаце третьем слова «включенные в перечни, установленные нормативными правовыми актами соответствующих государственных органов Республики Татарстан, а также их супруг (супругов) и несовершеннолетних детей» заменить словами «осуществление полномочий по которым влечет за собой обязанность представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«супруг (супругов) и несовершеннолетних детей лиц, указанных в абзаце третьем настоящего подпункта.».

8. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 22 апреля 2013 года № УП-329 «Об утверждении Перечня должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при замещении которых государственные гражданские служащие Республики Татарстан обязаны представлять сведения о своих расходах, а также о расходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей».

9. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
23 марта 2015 года
№ УП-308

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 22 декабрендәге 431-ФЗ номерлы федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә һәм коррупциягә каршы көрәшү эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы указына (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамада, преамбулада, 1 пунктта, 2 пунктның «а» пунктчасында «гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктның «в» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

в) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган вазыйфалары исемлеге атамасында «гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы һәм 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-328 номерлы һәм 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү бурычы граждан хезмәтен биләүгә дәгъва кылучы гражданга (алга таба – граждан) йөкләнә.

Керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү бурычы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган граждан хезмәте вазыйфаларының тиешле исемлегенә (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) кертелгән граждан хезмәте вазыйфасын хисап елының 31 декабренә биләүче Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәре) йөкләнә.»;

б) 3 пунктта «Вазыйфалар исемлегендә каралган» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6 пунктның «в» пунктчасында:

«әгәр алыш-бирешләр суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) әлеге алыш-бирешне башкару алдыннан килгән соңгы өч ел эчендә алган гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чоры алдыннан килгән соңгы өч ел эчендә алган гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

«алыш-биреш башкарылган» сүзләрен «әлеге алыш-бирешләр башкарылган» сүзләренә алмаштырырга;

г) 7 пунктта:

«Вазыйфалар исемлегенә кертелгән граждан хезмәте вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы» сүзләрен «граждан хезмәтенең башка вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы» сүзләренә алмаштырырга;

«2,3 һәм 5 пунктлар нигезендә» сүзләрен «2 пунктның беренче абзацы, 3 һәм 5 пунктлар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 8 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе (дәүләт хезмәтен биләүче зат) исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

е) 13 пунктта:

«алыш-биреш башкарылган» сүзләрен «алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш башкарылган)» сүзләренә алмаштырырга;

«алыш-бирешләрнең суммасы граждан хезмәте вазыйфасын биләгән затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан килгән соңгы өч ел эчендә алган гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «мондый алыш-бирешләр суммасы граждан хезмәте вазыйфасын биләгән затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чоры алдыннан килгән соңгы өч ел эчендә алган гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 15 пунктның икенче абзацында «Вазыйфалар исемлегенә кертелгән граждан хезмәте вазыйфасына» сүзләрен «алар биләүне дәгъва кылган граждан хезмәте вазыйфаларына» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-330 номерлы һәм 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы һәм 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 пунктның «в» пунктчасында:

«әгәр алыш-бирешләрнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) әлеге алыш-бирешне башкару алдыннан килгән соңгы өч ел эчендә алган гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап

чоры алдыннан килгән соңгы өч ел эчендә алган гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

«алыш-биреш башкарылган» сүзләрен «әлеге алыш-бирешләр башкарылган» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 12 пунктта:

«алыш-биреш башкарылган» сүзләрен «алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш башкарылган)» сүзләренә алмаштырырга;

«әгәр алыш-бирешләрнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) әлеге алыш-бирешне башкару алдыннан килгән соңгы өч ел эчендә алган гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чоры алдыннан килгән соңгы өч ел эчендә алган гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-237 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 14 августындагы ПУ-761 номерлы һәм 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәгә, 2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) әгәр килешү суммасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның (Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең) һәм аның хатынының (иренең) хисап елына кадәрге соңгы өч елдагы кеременнән артык булса, хисап елына (1 гыйнвардан алып 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (катнашу өлешләре, оешмаларның устав (кушылма) капиталларында пайлар) сатып алу буенча килешү башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы һәм 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 15 пунктта:

«б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәткәренең территориясендә аның счетлары (кертемнәре) булган, чит ил банкында акчалары һәм кыйммәтле әйберләре саклана торган чит дәүләтнең һәм (яисә) чит ил финанс инструментлары булган, яисә аның ихтыярыннан яисә аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярыннан тормаган шартлар буенча әлеге чит дәүләтнең законнары нигезендә компетентлы органнары тарафыннан кулга алынуы, куллану тыелуы белән бәйле рәвештә «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) файдалануны тыю турында» Федераль закон) таләпләрен үтәү мөмкин булмавы турындагы гаризасы;»;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $64^1$ статьясы нигезендә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт шартнамәсе яисә гражданлык-хокукый шартнамә төзү турындагы дәүләт органына бирелгән хәбәрнамәсе, әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарә итүенең аерым функцияләре граждан дәүләт органында вазыйфа биләгән вакытта аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кермәгән булса, әлеге гражданга комиссия тарафыннан алдарак бу оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләренә һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керү тыелган яисә әлеге гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган

оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында аның тарафыннан эшләр башкаруга рөхсәт бирү мәсьәләсе каралмаган булса.»;

б) 18 пунктта:

өченче һәм дүртенче җөмләләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр дә дәүләт хезмәткәре (аның вәкиле) комиссия утырышына килмәсә һәм дәүләт хезмәткәренең әлеге мәсьәләне аның катнашыннан башка хәл итү турында язмача үтенече булмаса, мәсьәләне карап тикшерү кичектерелә. Дәүләт хезмәткәре нигезле сәбәпсез кабаттан утырышка килмәсә, комиссия дәүләт хезмәткәреннән башка әлеге мәсьәләне карау турында карар кабул итә ала.»;

түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Әгәр дә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан (аның вәкиле) тору урынын алыштыру сәбәпле, ләкин комиссия утырышы уздыру вакыты турында аңа хәбәр итүнең барлык чаралары да күрелгән очракта комиссия утырышына килмәсә, комиссия дәүләт хезмәткәреннән башка әлеге мәсьәләне карау турында карар кабул итә ала.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $24^2$ пункты өстәргә:

«$24^2$. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулык итүче сәбәпләрне объектив һәм нигезле дип тану турында;

б) «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулык итүче сәбәпләрне объектив һәм нигезле түгел дип тану турында. Бу очракта комиссия дәүләт органы җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылыкка тарту чарасы кулланырга тәкъдим итә.»;

г) 25 пунктта:

«15 пунктның «а», «б» һәм «г» пунктчаларында» сүзләрен «15 пунктның «а», «б», «г» һәм «д» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

«21-24 һәм $24^1$ пунктлары» сүзләрен «21-24, $24^1$, $24^2$ һәм $25^1$ пунктлары» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы

дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы һәм 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктта:

«з» пунктчасында:

«тәэмин итү» сүзен «гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

«, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче гражданнарның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң алар белән федераль законнарда каралган очракларда хезмәт килешүе һәм (яисә) граждан-хокукый килешү төзелгән очракта хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле «л» һәм «м» пунктчалары өстәргә:

«л) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәве, чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр каршылыкларын булдырмау яисә җайга салу таләпләрен үтәүләре турында белешмәләрне, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын билгән гражданнар тарафыннан аларның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң федераль законнар белән каралган очракларда хезмәт шартнамәсе һәм (яисә) граждан-хокукый шартнамә төзүдәге чикләүләрне үтәве турында белешмәләрне анализлау;

м) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын билгән гражданнар тарафыннан аларның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң федераль законнар белән каралган очракларда хезмәт шартнамәсе һәм (яисә) граждан-хокукый шартнамә төзүдәге чикләүләрне үтәвен тикшерүне тормышка ашыру.»;

б) Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында Нигезләмәдә:

3 пунктта «әлеге вазыйфалар исемлегендә каралган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтенең башка вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы

Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында һәм Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «а» пунктчасының өченче абзацында, 1 пунктның «б» пунктчасындагы икенче абзацта «Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән исемлекләргә кертелгән» сүзләрен «алар буенча вазыйфалар башкару үзенең керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү бурычын китереп чыгаручы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктның «а» пунктчасындагы бишенче абзацта «муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән исемлекләргә кертелгән» сүзләрен «алар буенча вазыйфалар башкару үзенең керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү бурычын китереп чыгаручы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 1 пунктның «в» пунктчасындагы икенче абзацта «Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органы норматив хокукый актында билгеләнгән исемлеккә кертелгән» сүзләрен «алар буенча вазыйфалар башкару үзенең керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү бурычын китереп чыгаручы» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 пунктның икенче абзацындагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Указның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән затларның чыгымнарын контрольдә тоту турындагы карар чыгару өчен әлеге зат, аның хатыны (ире) яисә балигъ булмаган балалары тарафыннан белешмәләр бирелә торган ел (алга таба – хисап елы) алдыннан килгән календарь ел дәвамында хисап чоры алдыннан килә торган соңгы өч ел эчендә суммасы әлеге затның һәм аның хатынының гомуми кеременнән артып китә торган җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы,

кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталында катнашу өлешләре, пайлар) алу буенча алыш-бирешләр башкарылуы (алыш-биреш башкарылуы) турында җитәрлек мәгълүмат нигез булып тора.»;

д) 6 пунктта «Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2015 елның 2 февралендәге ПУ-71 номерлы» сүзләрен өстәргә.

е) 9 пунктның «б» пунктчасында:

өченче абзацта «Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органнары норматив хокукый актларында билгеләнгән исемлекләргә кертелгән, шулай ук аларның хатыннары (ирләре) һәм аларның балигъ булмаган балалары» сүзләрен «алар буенча вазыйфалар башкару үзенең керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү бурычын китереп чыгаручы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге пунктчаның өченче абзацында күрсәтелгән затларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының.».

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-329 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге Указ кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 23 март
№ ПУ-308